**ТАТАРСТАН Республикасы**
**Аксубай муниципаль районы**
**муниципаль беремлеге**
**Емелькино авылы**

**Республика ТАТАРСТАН**
**Аксубаевский**
**муниципальный район**
**муниципальное образование**
**село Емелькино**

# Совет Емелькинского сельского поселения

423056, Республика Татарстан, Аксубаевский муниципальный район, село Емелькино, ул. Центральная д.16
Тел.(8-84344-4-76-22) ОГРН 1021605364980, ОКПО 94318599,ИНН/КПП 1603000796/160301001

## КАРАР

### Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлеге составына керүче Черемушка авылында халык җыены нәтиҗәләре турында,

17 ноябрь 2022 ел № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә » Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы» Емелькино авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 05.11.2019 № 100 карары белән 2022 елның 17 ноябрендә гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде: « I төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, өлешчә мобилизацияләнгән затлардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш 2023 елда Аксубай муниципаль районының Емелькино авыл җирлеге Черемушка авыл территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә , алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтүгә ризамы:

1.Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- урамнарны торак пункт чикләрендә кышкы карап тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, эш өчен түләү);
-торак пункт чикләрендә вак таш белән капланган юл полотносын кору- (таш сатып алу (китерү) -вак таш, ЩПС; эш өчен түләү-грунт күтәрү, вак таш тутыру, ЩПС туздыру, су агызу торбаларын сатып алу)
-торак пункт чикләрендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу)

2.Күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;

- җәйге вакытта территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, мотокосилка өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү)

3.Күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;

- торак пункт чикләрендә урамнарны яктыртуны тәэмин итү өчен товарлар сатып алу, эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү;

4. Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә ягулык белән тәэмин итү

- тирән су насосын алу

| | «РИЗА» | «КАРШЫ» | «ТЫЕЛДЫМ» |
|---|---|---|---|

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 87 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 45 кеше кертелгән.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
"Риза"позициясе өчен 45 граждан тавыш бирде;
- "Каршы"позициясе өчен 0 гражданин тавыш бирде.
- "Тыелдым"позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде

Шуның нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Емелькино авыл җирлеге Черемушка авылында гражданнар җыены үткәрелде, гражданнар җыены нәтиҗәсе гамәлдә дип танырга

2 « I . Сорау буенча карар кабул ителде: 1 нче төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, өлешчә мобилизацияләнгән затлардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш 2023 елда Аксубай муниципаль районының Емелькино авыл җирлеге Черемушка авыл территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә , алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтүгә ризамы:

1.Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- урамнарны торак пункт чикләрендә кышкы карап тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, эш өчен түләү);

-торак пункт чикләрендә вак таш белән капланган юл полотносын кору- (таш сатып алу (китерү) -вак таш, ЩПС; эш өчен түләү-грунт күтәрү, вак таш тутыру, ЩПС туздыру, су агызу торбаларын сатып алу)

-торак пункт чикләрендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу)

2.Күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;

- җәйге вакытта территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, мотокосилка өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү)

3.Күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;

- торак пункт чикләрендә урамнарны яктыртуны тәэмин итү өчен товарлар сатып алу, эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү;

4. Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә ягулык белән тәэмин итү

- тирән су насосын алу

3. Әлеге карарны информацияне Емелькино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга http://aksubaevo.tatar.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырырга http://pravo.tatarstan.ru

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Емелькино авыл җирлеге башлыгы
Совет Рәисе, Н.И.Михайлова